| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 ноябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа
авылында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 20 ноябрендә 15.00 сәгатьтә ТР Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Тойгуҗа авылы, Үзәк урам, 48 йорт адресы буенча урнашкан Тойгуҗа авыл мәдәният йортын билегләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертүгә, Россия Армиясе сафларына срокглы хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге (көндезге) уку формасындагы студентларны түләүдән азат итәргә һәм алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

«1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Тойгуҗа авылында 2 (ике) данә янгын гидранты сатып алу);
2. Урамнарны яктырту җайланмасы: (урамнарны яктырту диодлы яктырткычлар сатып алу);
3. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу өчен бензин триммер сатып алу; Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу);
4. Узган еллардан калган үзара салым акчаларын Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабуга илтергә?

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Тойгуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә

www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин